БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№5.2016

Сабантуй Кыпере

0+

ISSN 0868-4545



ЯКШӘМБЕ | ДҮШӘМБЕ | СИШӘМБЕ | ЧӘРШӘМБЕ | ПӘНҖЕШӘМБЕ | ҖОМГА | ШИМБӘ | ЯКШӘМБЕ



© «Салават күпере», 2016 ел.

Безнең VKontakte битенә «Салават күпере» журналы белән төшкән фотоңны куй һәм тавыш җый!


МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!



Алинә, 6 яшь,
Рияз, 6 яшь, Азнакай.



Ильяр, 2 яшь,
Илсинә, 6 яшь, Саба.



Эльдан, 2 яшь,
Мәликә, 2 яшь, Азнакай.



Айзилә, 7 яшь, Апас.



Рамина, 6 яшь,
Әмирхан, 6 яшь, Азнакай.



Эльвина, 7 яшь, Казан.

ИГЕЛЕК АТНАСЫ



Елмай бу арада моңсуланып йөри. Елмаймый, дуслары белән дә аз сөйләшә. Моны күреп, дуслары:

– Нәрсә булды сиңа, Елмай? – дип сораштыра башладылар.

– Берни дә булмады. Миңа күңелсез генә, – диде кыз.

– Әйдә, кәефеңне күтәрер өчен без сине туңдырма белән сыйлыйбыз, – диде Шалай чын күңелдән.

– Рәхмәт, Шалай, кирәкми. Минем яраткан әти-әнием, кызыклы уенчыкларым, матур күлмәкләрем, үз бүлмәм бар. Шулай да никтер күңелсез миңа.

Дуслар Елмайга ничек ярдәм итәргә кирәклеген белмәгәч, Галим белән киңәшләшергә булдылар.

– Бу акыллы песи яхшы киңәш бирми калмас! – диде Шүркә.

Галим малайларны тыңлагач:

– Бар да аңлашылды! Мин кызга ничек ярдәм итәргә икәнен беләм! – дип, Елмайның өенә таба юл тотты. Шалай белән Шүркә берни дә аңламадылар, ләкин песи артыннан ашыктылар.

– Әйдәгез, игелек атнасы оештырабыз! Һәрберебез җиде көн буе бары тик яхшы эшләр башкарырга тиеш! – диде Галим.

Дуслар башта уйга калды. Аннары, елмаешып, төрле якка йөгерештеләр. Шалай атна буе кош-кортларны, җәнлекләрне кайгыртты: җимлекләр ясап элде, кыштан калган чүпләрне ташлады. Шүркә урманга барып, Шүрәле бабасына һәм Шүрбикә әбисенә булышты: өй җыештырды, тәмле әйберләр әзерләште. Елмай да озак уйлап тормады: матур уенчыкларын һәм матур күлмәкләрен башка балаларга бүләк итте.

Көн артыннан көн узды. Дуслар арган булсалар да, һәрберсенең йөзендә елмаю, күзләрендә якты нур балкыды. Елмай да бертуктаусыз көлде, дуслары белән яңа хис-кичерешләрен уртаклашты.

Дуслар моннан соң игелекләрне бер атна гына түгел, ә ай буе, хәтта, ел дәвамында эшләргә булдылар.

Әйе шул, игелек иткән игелек күрер!

Дускай, «Салават күпере» журналы хезмәткәрләре 25 майдан 1 июньгә кадәр «Игелек атнасы» оештырып, «Республика балалар йорты»нда яшәүче нәни дусларына бүләкләр җыя. Әлеге балалар «Инфантрини» һәм «Педиашур» катнашмаларына (смесь), 4 нче һәм 5 нче үлчәмле аслыкларга (подгузник) һәм башка әйберләргә мохтаҗ. СИН ДӘ БЕЗГӘ КУШЫЛА АЛАСЫҢ!

Адресыбыз: Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.



Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, публицист, җәмәгать һәм мәдәният эшлеклесе Ренат абый Харис 1941 елның 6 маенда Ульян өлкәсенең Цильна районы Кәшә авылында туа. Буа шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтында укый.





Ренат Харис – 1990 елдан башлап Татарстан Республикасы Дәүләт Советының өч чакырылыш халык депутаты. 1995-1999 елларда ул Дәүләт Советы Рәисенең урынбасары вазыйфаларын башкара. Татарстанның дәүләт символлары буенча эшче төркемне җитәкли һәм Дәүләт флагын, гербын, гимнын кабул итүгә әзерли.

Шулай ук Ренат Харис – кырыктан артык поэма, дистәгә якын шигъри цикллар, йөз иллеләдән артык җыр, романслар, кантаталар, ораторияләр авторы.

Балалар исә Ренат абый Харисны нәни укучылар өчен язылган «Без кунакка барабыз!» һәм «Матур өй» китапларындагы шигырьләре өчен ярата.







Акбай

Арт аягына баскан,
биш-алты медаль аскан.
Сикереп бии Акбай.
Акбай – акыллы маэмай.

Койрыгын селкетә –
ул тәмле азык көтә.
Конфет ашамый Акбай.
Акбай – акыллы маэмай.

Биеде дә тирәмдә,
барып ятты чирәмгә.
Тузанга ятмый Акбай.
Акбай – акыллы маэмай.

Он по пустякам не лает,
На груди медали носит.
Ловко прыгает Акбай.
Наш Акбай смышлёный песик.

Подбежал, хвостом виляет,
Смотрит – угощенье просит.
Но конфет не ест Акбай.
Наш Акбай смышлёный песик.

Он в сторонку отошел,
Лег – в траву уткнулся носик.
В грязь не ляжет наш Акбай.
Наш Акбай смышлёный песик.

Сөенеч

Сөенеч! – песиебез хәзер өч:
зурысы – әни песи,
икесе – бәби песи.
Бәбинең берсе ап-ак,
ә берсе – кара колак.
Агына исем – Аппак,
кара колакка – Шапшак.

Радость

Радость! Радость! Посмотри:
наших кошек стало – три:
самая главная мама кошка,
рядом котята
размером с ладошку.
Белый один
от хвоста до макушки,
а у другого чёрные ушки.
Белый котёнок будет – Чистюля,
а черноухому имя – Грязнуля.



Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА

Перевод Талии ШАРАФИЕВОЙ

СИНЕҢ ДУСЛАРЫҢ КҮП ИКӘНЕН БЕЛӘБЕЗ.
ШУҢА КҮРӘ ДУСЛЫК ТӨШЕНЧӘСЕ ДӘ СИҢА ТАНЫШТЫР.
БИРЕЛГӘН ТАҖЛАРДАН ДУСЛЫК ЧӘЧӘГЕН ТӨЗЕП КАРА.
МОНЫҢ ӨЧЕН АЛАРНЫ КИСЕП АЛ ҺӘМ ЧЫН ДУСЛАРГА ХАС БУЛГАН СЫЙФАТЛАРДАН ГЫНА ЧӘЧӘК ЯСА.



ДУСЛЫК ЧӘЧӘГЕ

КАЙГЫРТУЧАН

КӨНЧЕ

ЯГЫМЛЫ

АРАЛАШУЧАН

САРАН

ИГЕЛЕКЛЕ

ИХЛАС

ЯРДӘМЧЕЛ

БАТЫР

ТЫЙНАК

ТУГРЫ


ЯЛГАНЧЫ



РӘСЕМНЕ БУЯ.
МУЗЕЙГА ҮЗЕҢ ИСЕМ ТАП
ҺӘМ ЯЗЫП КУЙ.
СИНЕҢ НИНДИ МУЗЕЙЛАРГА
БАРГАНЫҢ БАР?


ДУСЛАРГА МУЗЕЙГА БАРЫП
ҖИТӘРГӘ ЯРДӘМ ИТ.







РЕБУСНЫ ЧИШ.






’Т=П



”’’



се

ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ҖАВАБЫН ТАП.

Кулдан-кулга йөри ул,
Бөтен телдә сөйли ул,
Белмәгәне юк аның,
Көзгесе ул дөньяның.

Бер байлык бар – янмый,
Карак та урлый алмый,
Төшеп тә югалмый.



Данияр ГЫЙЛЬМЕГАЯНОВ,
Әгерҗе, Яңа Бәзәкә
башлангыч мәктәбе, 7 яшь.



Эмилия ХӘКИМОВА,
Азнакай, 18 нче балалар
бакчасы, 6 яшь.



Азат РӘХМӘТУЛЛИН,
Казан, 54 нче мәктәп,
3 нче сыйныф.



Илһам АЗИЗОВ,
Казан, 54 нче мәктәп,
2 нче сыйныф.



Әдел ХАҖИЕВ,
Әгерҗе, Яңа Бәзәкә
башлангыч мәктәбе, 8 яшь.



Ралинә ЗӘМДИХАНОВА,
Казан, 170 нче балалар
бакчасы, 4 яшь.



Милана АХУНОВА, Казан,
242 нче балалар бакчасы,
6 яшь.



Эрик ФӘТХУЛЛИН, Казан,
399 нчы балалар бакчасы,
6 яшь.



Ратмир ГАЛИЕВ,
Казан, 170 нче балалар
бакчасы, 4 яшь.

СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!

БАБАЕМА

Онытмыйк, дуслар,
Бабайлар хакында.
Киләчәк хакына
Кергәннәр ялкынга.
Минем бабам да
Сугышта булган.
Анда меңләгән
Дошманны кырган.
Курыкмаган ул
Дошман танкыннан.
Һәрвакыт алгы
Сызыкта булган.

Югалтуларсыз
Сугыш бармаган.
Бабам да беркөн
Нык яраланган.
Госпитальдән ул
Терелеп чыккан.
Сыңар аяксыз
Авылга кайткан.
Батырлык өчен
Орден-медальләр
Герой күкрәген
Бизәп торганнар.

Кайткач та бабам
Гаилә корган.
Унөч баланың
Әтисе булган.
Бик горурланам
Уйлыйм да шуны.
Мин дә бит аның
Бер оныкчыгы.
Тынычлык телим
Якты дөньяга!
Шигырем дога
Булсын бабама...

Динә ШӘВӘЛИЕВА,
Апас, Каратун урта
мәктәбе, 2 нче сыйныф.

ӘБИЕМ – ВЕТЕРАН

Әбием минем – ветеран,
Көтә җиңү бәйрәмен.
Үткәннәр турында сөйли,
Кулга алып бәйләмен.
Оныкларына көн саен,
Хәтер йомгагын сүтә.
Җиңү китергән язга да
Җитмеш беренче үтә.
Шатлык яшьләре аша
Әбием укый дога.
– Имин дөньяда яшәргә
Насыйп итсен, и Хода!

Рания САФИНА, Мөслим,
Мари Буләр урта мәктәбе,
5 нче сыйныф.

ВАТАН САКЧЫЛАРЫ

Әтием ракетчик булган,
Чын танкист – дәү әтием.
Дошманга каршы сугышта
Көрәшкән карт әтием.
Мин дә үсеп егет булгач,
Шушы юлдан атлармын!
Туган илемнең чикләрен
Бик тырышып саклармын!
Илем күге тыныч торсын,
Кояшлы булсын һәр көн.
Кайгы җилләре исмәсен,
Бәхетле булсын һәркем!

Әмир ИСМӘГЫЙЛЕВ,
Яшел Үзән, Бакырчы,
2 нче сыйныф.

ХӘЗИНӘБЕЗ

18 май көнне сезне бергәләп музейларга сәяхәт итәргә чакырабыз! Әйдә, дускай, юлыбызны «Хәзинә» милли сәнгать галереясеннән башлыйбыз.

Әлеге уенны чираттан кубик атып, чыккан сан буенча йөреш ясап, бер-бер артлы уйнарга кирәк. Ук белән күрсәтелгән санга эләксәң, биремне үтәргә онытма!

Хәзинә – икенче төрле байлык, муллык дигәнне аңлата. Галереядә нинди байлыклар саклана? Шуларны рәсемдә яса.



СТАРТ

1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12 13 14 15 16 17 18 19 20 21 ... 32 33

Эшләр «Хәзинә» милли сәнгать галереясе фондыннан алынды.








Әлеге эшләрнең авторы – татар һөнәри сынлы сәнгатенә нигез салучы Бакый Урманче. Алар нинди сәнгать төренә карый?

«Хәзинә» галереясе 2005 елда Казан Кремле музей-тыюлыгында элеккеге Юнкерлар укуханәсе бинасында ачыла. Галерея Татарстан рәссамнары һәм сынчыларының иң матур әсәрләреннән тупланган.

Данлыклы татар рәссамы, танылган портрет остасы – Харис Якупов Мария Щербакка багышлап *картина ясаган. 17 яшендә Мария һәлак булган* абыйсы урынына фронтка китә. 148 нче укчылар дивизиясендә пулеметчы була һәм сугышта зур батырлыклар күрсәтә.

Ә син Бөек Ватан сугышы турында ниләр беләсең?





Татарстан һәм Россиянең атказанган рәссамы Илдар Зариповның картинасы ничек атала?

Дымков уенчыгы – рус халкының һөнәри сәнгате. Ул кул белән кызыл балчыктан ясала. «Хәзинә» галереясендә төрле дымков уенчыклары саклана. Уенчыкны үрнәктәгечә буя.



ЯШӘҮ ЧЫГАНАГЫ

Кешеләр сусыз, һавасыз тора алмаган кебек, кояшка да мохтаҗ. Чөнки кояш нурлары җиребезне яктылык һәм җылылык белән тәэмин итә. Кояш – Җир планетасында яшәешне тотып торучы, кешеләр өчен иң кирәкле йолдыз. Димәк, без бу иң якты күк җисеме турында күбрәк белергә тиеш.

Кояш – Җир шарына иң якын бердәнбер йолдыз. Ул үзенең тирәсендә урнашкан күк җисемнәре белән Кояш системасын барлыкка китерә. Аңа Кояш, Ай һәм 8 зур планета: Меркурий, Венера, Марс, Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун, Җир керә. Шулай ук Кояш тирәсендә кечкенә планета, комета һәм метеоритлар бар.


Күктә 100 миллиардтан артык йолдыз исәпләнә, ләкин аларның иң яктысы – Кояш.

Кояш 4,6 миллиард ел яна. Ул түгәрәк формасында, бик зур водород болытыннан һәм йолдыз тузаныннан тора. Аның авырлыгы Җирнекенә караганда бик күп тапкырга зуррак һәм ул аннан 149,6 миллион километр ераклыкта урнашкан.

3 май көнне бөтен дөньяда «Кояш көне» билгеләп үтелә. Дөрестән дә, кояш энергиясенең мөмкинлекләре бик зур. Кояштан көч алып эшләүче батареялар да бүгенге көндә киң кулланыла.

ЧЫГАНАК – ИСТОЧНИК – RESOURCE [РИ'ЗО:С]
КҮК ҖИСЕМЕ – НЕБЕСНОЕ ТЕЛО – CELESTIAL BODY [СИ'ЛЭСТЭЛ 'БАДИ]
ТӘЭМИН ИТҮ – ОБЕСПЕЧИВАТЬ – PROVIDE [ПО'ВАЙД]

• БАШКА КҮК ҖИСЕМНӘРЕ ТУРЫНДА НИЛӘР БЕЛӘСЕҢ?
• РӘСЕМДӘГЕ МИСАЛЛАРНЫ ЧИШ ҺӘМ КҮК ҖИСЕМНӘРЕН ТИЕШЛЕ ТӨСКӘ БУЯ.



1 - ЗӘҢГӘРСУ; 2 - ЗӘҢГӘР; 3 - САРЫ; 4 - КЫЗЫЛ;
5 - КЫЗГЫЛТ КӨРӘН; 6 - СОРЫ; 7 - САРГЫЛТ.

Зиннур
ХӨСНИЯР

МӘЧЕТ

Булат үзен бик башлы малайга саный. Күп беләм дип уйлый ул, чөнки мәктәпкә йөри бит. Сумкасы тулы китап.

Ә бабасы мәктәптә укымаган. Алар яшь чакта мәчеткә йөргәннәр. Булат мәчетне икенче төрле клуб дип атый. Чөнки анда клубтагы кебек җырлыйлар. Аерма шунда гына: клубта гармун белән, мәчеттә гармунсыз гына. Тагын... тагын әле клубта кызлар җырласа, мәчеттә – бабайлар... Дөресрәге, мулла бабай җырлый.

Ходайга шөкер, бу сүзләрне Булат күрше малае Искәндәргә әйтергә өлгерми калды. Югыйсә, үзенең күп белүе белән мактанып алырга исәбе юк түгел иде. Нигә шулаймы? Чөнки Искәндәр бабасына ияреп мәчеткә барды! Һәм ул исе китеп, мактанып һәм, әлбәттә, күп нәрсәләр белеп кайтты! Дөресен белгән! Әй, сөйләп җибәрде Искәндәр. Мәчет ул бернинди клуб түгел, ул – гыйбадәтханә. Икенче төрле – Аллаһы Тәгалә йорты икән.

Иң беренче мәчет Мәдинә шәһәреннән ике чакрым ераклыкта урнашкан Кубә шәһәрендә Мөхәммәт пәйгамбәр заманында ук төзелгән. Ул дүрт почмаклы агач бинаның түбәсе хөрмә агачы яфраклары белән ябылган булган.

Хәзерге заманда мәчетләр бик матур эшләнә. Аларның манаралары күккә ашкан була. Манара очындагы ай кояш нурында балкып тора. Мәчетнең эченә килеп керүгә үк җанга тынычлык, рәхәтлек иңә.

Кеше дөньядагы барлык вак һәм зур мәшәкатьләрен онытып, Ходай каршында дога кыла.



Равил АЙДАРОВ рәсеме




ТӘМЛЕ КАТЛАМА

Дуслар, минем сөт яратканымны беләсез инде. Ә менә куертылган сөтне сез дә бик тәмләп ашыйсыз. Чөнки аңа шикәр комы кушып ясыйлар. Бу тәмле әйбер моннан 160 ел элек уйлап табылган. Рогачев шәһәрендә хәтта куертылган сөт савыты һәйкәле бар. Бүген куертылган сөт белән тәмле катлама ясау ысулын сезгә дә тәкъдим итәм.

КИРӘКЛЕ ӘЙБЕРЛӘР:

- 200 гр. печенье
- 100 гр. йомшартылган ак май
- 4-5 аш кашыгы какао
- куертылган сөтнең өчтән бер өлеше
- азык-төлек пленкасы






1 САВЫТТА ПЕЧЕНЬЕНЫ ВАКЛА. ШУНДА УК ЙОМШАРТЫЛГАН МАЙНЫ САЛЫП БОЛГАТ.





2 АЛАР ӨСТЕНӘ КАКАО САЛ ҺӘМ ТАГЫН БЕР КАТ БОЛГАТ.





3 КУЕРТЫЛГАН СӨТНЕ КУШ ҺӘМ БЕРТӨРЛЕ МАССА ЯСА.





4 ӘЗЕР МАССАНЫ ПЛЕНКАГА САЛ ҺӘМ ТӘГӘРӘТЕП ТӨР.





5 КАТЛАМАНЫ 5-6 СӘГАТЬКӘ СУЫТКЫЧКА КУЙ.

ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Әмирхан ЕНИКИ

БАЛА

Хикәядән өзек

...Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенә, һәм аңарда кузгалган беренче теләк – баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды. Беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды. Бала куркуыннан:

– Әни! – дип кычкырып җибәрде һәм, җиләген йомарлаган кулы белән Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп еларга кереште.

Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты. Шундый кыска вакыт үтүгә карамастан, рота шактый ераклашкан иде инде. Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.

Бала елап арыган, күрәсең; тиз арада аның елавы тавышсыз үксүгә әйләнде. Зариф кесәсеннән бер шикәр кисәге чыгарып, тузанын өргәләп, балага тоттырды. Бала башта башын селкегән булды, аннары шикләнеп кенә буш кулы белән шикәрне алды һәм йомарлап күкрәгенә кысты.

Зариф йомшак тавыш белән:

– Аша, аша! – диде һәм баланың аркасыннан сыйпап, сөеп куйды. Балага шул җитә калды: ул үксүеннән туктады, тынычланган кебек булды һәм, Зарифның кулында акрын гына селкенеп, тирә-ягына каранып бара башлады. Зариф баланың юка киеме аша йомшак

Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА

тәнен, җылысын, тәмле исен тоя иде. Ниндидер бер ләззәтле сагыну белән шул йомшак тәнне, шул тәмле бала исен тагы да ныграк тоярга, ничектер үзенә сеңдерергә теләгәндәй, ул баланы акрын гына кыса, аркасыннан сыйпый... Һәм аның йөрәге төбеннән әйтеп биреп булмый торган сөенечле бер ярату хисе җылы дулкын булып күтәрелә бара иде. Зарифның да бит өч яшьлек Фәридәсе бар. Зариф та бит әти, һәм, бәлки, шушы минутта ул үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр, киресенчә, бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. Ул, баланың йомарлаган кулын тотып, кипкән иреннәренә тидереп алды. Акрын, назлы гына:

– Әтиең, әниең бармы? – дип сорады, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.

Бала ачык тавыш белән җавап кайтарды:

– Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.

Зариф, елмаеп, балага күтәрелеп карады:

– Шулаймыни? Кара син, ап-аклар икән... Ә әтиең кайда соң?

– Китте.

– Кая китте?

– Белмисеңмени? Фронтка, – диде бала һәм аз гына тынып торганнан соң исенә төшкәндәй, – ул лейтенант, – дип куйды...



ХИКӘЯНЕ ТУЛЫСЫНЧА УКЫП ЧЫК.
ЗАРИФНЫҢ БАТЫРЛЫГЫ НӘРСӘДӘ?
ЗАРИФКА БАЛА КЕМНЕ ХӘТЕРЛӘТӘ?
ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТАГЫН НИНДИ ХИКӘЯЛӘРЕН ЯРАТЫП УКЫЙСЫҢ?

Нариман
ДИМӨХӘММӘТОВ

Бишенче дәрес:

ТАНЫШУ

Кешенең исеме аның өчен иң матур, якын сүз дип ишеткәнем бар. Шуңа сөйләшкәндә дусларымның исемнәрен ешрак кабатларга тырышам. Кеше белән танышканда да тизрәк: «Исемегез ничек?» – дип сорыйм. Кызык, ә кытайча бу сорау ничек яңгырый икән?



Кытай телендә [jiaò] «Исемләү, атау» һәм [shén me] «Нәрсә?» иероглифларын бергә кушкач, [ni jiaò shén me] «Исемең ничек?» соравы килеп чыга.

你叫什么

[ni jiaò shén me]
ИСЕМЕҢ НИЧЕК?

КҮНЕГҮ

Үрнәк буенча яңа иероглифларны яз.

叫

什

么

ОНЫТМА

! [jiaò] «Исемләү, атау» сүзендә [j] авазы [дзь] дип укыла.
[shén me] «Нәрсә?» иероглифында басым [shén] сүзенә куела.

Диалог төзеп сөйләшеп карагыз.

– 你叫什么? ИСЕМЕҢ НИЧЕК?
[ni jiaò shén me]

– 我叫... ! МИНЕМ ИСЕМЕМ ...
[wǒ jiaò ...]



Intertat.ru электрон газетасы –

Татарстанның тормышы, халыкның яшәеше, республикадагы вакыйгалар турында яза торган уникаль интернет-ресурс.

Бездә:
- сәяси, икътисади, иҗтимагый, дини яңалыклар;
- кызыклы һәм актуаль вакыйгаларга күзәтү;
- аналитик мәкаләләр;
- көнүзәк темалар хакында белгечләр фикере;
- әңгәмәләр;
- спорт һәм мәдәни чаралардан фото һәм видеорепортажлар;
- шоу-бизнес яңалыклары.

Intertat.ru сайтының махсус сәхифәсе – «Яшь әни».

Анда бала табу, үстерү, тәрбияләү турында кызыклы һәм файдалы мәгълүмат табарга, йолдызлар фикере, белгечләр киңәшен укырга мөмкин. Балага нәрсә ашатырга, аның сәләтләрен ничек ачарга, чит телләргә кайчан өйрәтергә – шушы һәм башка күп кенә кызыклы темаларга язмалар безнең махсус «Яшь әни» рубрикасында.

Электрон газетаны Татарстанда яшәүчеләр генә түгел, ә чит төбәкләрдә, чит илләрдә гомер итүче татарлар һәм, гомумән, республика белән кызыксынучылар да үз итә. Intertat.ru язмаларын татарча латин графикасында да укып була. Сез дә керегез, укыгыз, фикерләрегез белән уртаклашыгыз!



Реклама 12+

Яшь әни

Безне барлык социаль челтәрләрдә табарга була:


vk.com/intertatgazeta


twitter.com/intertatov


facebook.com/Intertatru/


ok.ru/group/53992841281766


Instagram Intertat.ru

№5 (314) – 2016

**Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит с марта 1990 года.**

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР (ХӨСНЕТДИНОВ Зиннур Зыятдин улы)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ (ХӨСНЕТДИНОВА Зилә Зиннур кызы)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 21.04.16 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-1028. Тираж: 10380 данә.

Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле. Индекс: П2339.


Тышлыкта Казанның 26 нчы лицей укучысы Даминика Косарева рәсеме.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

МИЛЛИ КУРЧАК



Түбәтәй

Читек

Күлмәк

Камзул

Чалбар

**Дускай,
Шалайны татар
халкының милли
киемнәренә киендер. Моның
өчен үрнәктәге кием-салым
элементларын кисеп ал һәм
ак төстәге каптыргычлар
белән курчакка беркет.
Күлмәкләрнең тарихы
турында salavatkupere.com
сайтыннан укый аласың.**